**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 24 август

№ 617

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында» 2014 ел, 29 август, 619 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында» 2014 ел, 29 август, 619 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә бәян итеп (кararга теркәлә), үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\617.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 29 август, 619 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 24 август, 617 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү максатларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Конкурс ел саен 1 сентябрьдән 15 майга кадәр үткәрелә.

1.3. Конкурсны оештыручылар – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы.

1.4. Конкурс баллар системасы буенча үткәрелә.

2. Төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр

2.1. Бу Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

«Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы (алга таба – мобиль кушымта) – iOS яки Android операция системалары базасында фото- яки видеохәбәрләр тапшыру өчен җайланмаларга мобиль кушымта;

мәгариф порталы – «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» порталы https://edu.tatar.ru/;

катнашучының шәхси кабинеты – мобиль кушымтадагы шәхсиләштерелгән эш киңлеге, аңа керү башкалар керүдән якланган тоташтыру ярдәмендә гамәлгә ашырыла;

фото- яки видеохәбәр – модерациягә мобиль кушымта ярдәмендә кергән, Татарстан Республикасы территориясендә кирәкмәгән урында (каты көнкүреш калдыклары өчен (алга таба – калдыклар өчен) контейнерлар куярга мәйданчык, калдыкларны вакытлыча куеп тору өчен чүплек савыты белән җиһазландырылмаган урында) калдыклар булу турында сөйли торган сурәтне үз эченә алган хәбәр;

модерация – фото- яки видеохәбәрләрне карау барышында аларга алдан экспертиза һәм мониторинг үткәрү;

модератор – Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы.

## 3. Конкурсның максатлары

3.1. Конкурсның төп максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын әйләнә-тирә мохитнең торышын яхшырту буенча практик эшкә җәлеп итү;

халыкка электрон рәвештә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне популярлаштыру;

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучыларында актив тормыш позициясе тәрбияләү.

## 4. Конкурсның номинацияләре

4.1. Конкурс шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү оешмалары арасында түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1 – 4 сыйныфлар, 5 – 8 сыйныфлар, 9 – 11 сыйныфлар категорияләрендә «Иң актив укучы»;

1 – 4 сыйныфлар, 5 – 8 сыйныфлар, 9 – 11 сыйныфлар категорияләрендә «Иң актив сыйныф»;

«Иң актив мәктәп».

## 5. Конкурста катнашу тәртибе

5.1. Конкурста Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының мәгариф порталында һәм мобиль кушымтада теркәлгән укучылары (алга таба – катнашучы) катнашырга хокуклы.

5.2. Конкурста катнашу өчен түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

iOS яки Android системасына яраклы җайланмага мобиль кушымта куярга;

мобиль кушымтада теркәлергә, моның өчен теркәү формасының тиешле тәрәзәсендә мәгариф порталы логинын (катнашучының шәхси кабинеты белән «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» мәгълүмат системасыннан укучының логины арасындагы элемтәне тәэмин итү өчен) кертергә кирәк;

фото- яки видеохәбәрләрне мобиль кушымта аша җибәрергә, җибәрелә торган хәбәрләр саны чикләнмәгән.

5.3. Модератор фото- яки видеохәбәрләр кергән көннән өч көн эчендә фото- яки видеохәбәрне Конкурста катнашуга кертү турында яки Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту хакында карар кабул итә, бу турыда катнашучыга аның шәхси кабинеты аша хәбәр итә.

5.4. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә, әгәр дә фото- яки видеохәбәр:

кирәкмәгән урында калдыклар өеме булуны күрсәтмәсә;

бу Нигезләмәнең 1.2 нче пунктында билгеләнгән вакытны бозып кертелсә;

фотодагы- яки видеодагы сурәт үзенең күренеше, урыны һәм эшләнгән көне буенча алдан җибәрелгәнгә охшаса;

раса, этник, җенси, дини, социаль билгеләр буенча дискриминацияләү һәм нәфрәт пропагандалауга, азчылыкның, балигъ булмаганнарның хокукларын

чикләүгә, аларга теләсә нинди рәвештә зыян сала яки зыян салырга чакыра торган; башка катнашучыларны, башка затларны яки оешмаларны кимсетүне үз эченә алган мәгълүмат булса.

5.5. Фото- яки видеохәбәрне Конкурста катнашуга кертү турында карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан фото- яки видеохәбәрне Конкурста катнашуга кертү турында карар кабул иткән көннән өч көн эчендә катнашучыга 1 балл исәпләнә.

5.6. Видеохәбәрдә кирәкмәгән урында житештерү һәм куллану калдыкларын чыгару (автомобиль транспорты белән) процессы күрсәтелгән очракта, видеохәбәрдә транспорт чарасы калдыкларны чыгару вакытында, траспорт чарасының маркасы һәм дәүләт номеры, әйләнә-тирә мохит: калдыклар (мәсәлән, төзелеш, көнкүреш, агач калдыклары һ.б.), чыгарылган калдыкларның бөтен күләме һәм чүплек мәйданы күрсәтелгән булу шарты белән, катнашучыга эксперт комиссиясе карары буенча 10 балл исәпләнә.

## 6. Эксперт комиссиясе

6.1. Җиңүчеләрне билгеләү һәм Конкурска нәтиҗәләр ясау өчен, эксперт комиссиясе төзелә, аның составы һәм эш регламенты 1 майга кадәр Конкурсны оештыручыларның уртак боерыгы белән раслана.

6.2. Эксперт комиссиясе экологик күзәтчелек һәм экологик белем бирү өлкәсендәге әйдәп баручы белгечләр арасыннан төзелә.

6.3. Эксперт комиссиясе укучыларның, сыйныфларның һәм Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының рейтингларын карап тикшерә, иң күп балл җыйган катнашучыларның фото- яки видеохәбәрләренә экспертиза үткәрә һәм ачык тавыш бирү юлы белән һәр номинация буенча Конкурста җиңүчеләрне билгели.

6.4. Эксперт комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, эксперт комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч санала.

6.5. Эксперт комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм барлык эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана.

## 7. Йомгаклар ясау тәртибе

7.1. Конкурс үткәрелгән чорда модератор тарафыннан фото- яки видеохәбәрләрнең автоматлаштырылган мониторингы алып барыла һәм бары тик Конкурсны оештыручылар өчен генә ачык булган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары, укучылары һәм сыйныфлары рейтинглары төзелә.

7.2. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе:

«Иң актив укучы» номинациясендә – бер катнашучыдан иң күп фото- яки видеохәбәрләр саны буенча;

«Иң актив сыйныф» номинациясендә – сыйныфта фото- яки видеохәбәрләр җибәргән укучыларның иң күп проценты буенча;

«Иң актив мәктәп» номинациясендә – мәктәптә фото- яки видеохәбәрләр җибәргән сыйныфларның иң күп проценты буенча.

7.3. Номинацияләрнең һәр категориясендә җиңүчеләр санын эксперт комиссиясе билгели.

7.4. Эксперт комиссиясе Конкурска йомгакларны 1 июньгә кадәр ясый.

7.5. Йомгаклар ясалганнан соң, Конкурста җиңүчеләргә тантаналы бүләкләү чарасында дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

## 8. Конкурсны оештыручылар

8.1 Конкурсны оештыручылар:

Конкурсны үткәрү мәсьәләләре буенча катнашучыларга үз вакытында мәгълүмат бирә;

Конкурсны үткәрү барышы һәм аның йомгаклары турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итә;

Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыра.

---